ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.11.2025 г. Казань № 279-32/кс-2025

Түбән Кама муниципаль районының «Татэнерго» акционер җәмгыяте өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга 2025 елга тарифлар билгеләү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.12.2024 ел, №728-211/кс-2024 карарының үз көчен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Югары судының 3а-489/2025 номерлы эш буенча 16.05.2025 елгы карарын һәм Гомуми юрисдикциядәге дүртенче апелляция судының 09.09.2025 ел, №66а-998/2025 апелляция билгеләмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 12.11.2025 ел, №23-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районы «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Татэнерго» АҖ) өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында җиткерелә торган кайнар суга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Татэнерго» АҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2025 елга Түбән Кама муниципаль районының «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тарифлар билгеләү турында» 2024 елның 20 декабрендәге 728-211/кс-2024 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
12.11.2025 № 279-32/кс-2025
карарына кушымта

## Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Татэнерго» АҖ тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2025 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Кайнар су белән тәэмин итүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тариф (бер компонентлы), сум/куб.м | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы | | | | | | | |
| | | изоляцияләнгән торәкләр белән | | изоляцияләнмәгән торәкләр белән | | изоляцияләнгән торәкләр белән | | изоляцияләнмәгән торәкләр белән | |
| | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | |
| | | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | | | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | | | |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | | | | | |
| 1 | «Татэнерго» АҖ | | | | | | | | |
| 1.1 | халык (тарифлар НДС белән күрсәтелгән)* | 220,00 | 205,84 | 236,99 | 222,26 | 265,97 | 248,76 | 286,62 | 268,72 |
| 1.2 | башка кулланучылар (тарифлар НДС исәбеннән башка күрсәтелгән) | 183,33 | 171,53 | 197,49 | 185,22 | 221,64 | 207,30 | 238,85 | 223,93 |

* Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге